ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында
2024 елда үзара салым кертү турында

2023 елның 21 октябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең Тубылгы Тау авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәрбер гражданнан, көндезге бүлектә укучы студентлар, сугыш ветераны, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы көчләре хәрби хезмәткәрләре, 1 нче төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә 2024 нче елда үзсалым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

3. Тубылгы Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмәгыйлев

СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ